| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

13.04.2018 г.Казань № 926-р

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының:

«Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.06.2012 № 2159-р карарын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 19.12.2012 теркәлгән, регистрация номеры 1746);

«Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне

хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 30.06.2012 № 2159-р карарына үзгәрешләр кертү турында» 05.08.2014 № 1595-р карарын (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 12.09.2014 теркәлгән, регистрация номеры 2427) көчен югалткан дип таныырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Галиев Артур Ирек улына йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.04.2018 № 926-р
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге регламент Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар: юридик затлар –Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләре һәм Татарстан Республикасының автоном, бюджет, казна учреждениеләре, Татарстан Республикасының дәүләт казна предприятиеләре.

Гариза бирүчеләр һәм дәүләт хезмзте күрсәтелү вакытында юридик зат исеменнән эш итүче затлар булып юридик затның җитәкчесе, вәкаләтле вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле (алга таба – гариза бирүчеләр) чыга.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.3.2. Белешмә телефоннары:

Министрлыкның Мөлкәт идарәсенең Дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге (алга таба – Бүлек): 221-40-27, 221-40-26, 221-40-79;

Министрлыкның Мөлкәт идарәсенең Торак кучемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге (алга таба – Бүлек): 221-40-29, 221-40-86.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

Мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктлардагы дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Гражданнар кодексы - (алга таба – ГК РФ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1994, № 32, 3301 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 ел, 12 январь, № 7-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 7-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1996, № 3, 145 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Федеральным законом от 24 июля 1998 № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» (алга таба – Федераль закон № 124-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998 года, № 31 3802 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) турында» 2002 ел, 25 июнь, 73-ФЗ номерлы Федераль закон

(алга таба - Федераль закон № 73-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 26, 2519 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 14 ноябрь 2002 ел № 161-ФЗ Федераль закон (алга таба - Федераль закон № 161-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2002, № 48, 4746 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Конкуренцияне саклау турында» 26 июль 2006 ел № 135-ФЗ Федераль закон (алга таба – Конкуренция турында Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 31, 3434, б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Автоном учреждениеләр турында” 3 ноябрь 2006 ел № 174-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 174-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2006, № 45, 4626 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 27 июль 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010 ел, № 31, 4179 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел, № 218-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон № 218-ФЗ) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2015, № 29, 4344 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, ст. 2338);

«Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 ел, 26 июль, № 35-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – ТР Законы № 35-ЗРТ) (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7, 621 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 0985 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләти (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.05.2010 № 83-ФЗ Федераль Законны Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп оештыру, төрен үзгәртү һәм бетерү ягыннан тәртип урнаштыру, шулай ук, Татарстан Республикасындагы дәүләт учреждениеләрен гамәлгә куючының һәм мөлкәт иясенең функцияләрен һәм вәкаләтләрен регламентацияләү ягыннан Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.10.2010 № 820 карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 45, 2039 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы автоном яки бюджет учреждениесенең аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәте төрләрен һәм исемлекләрен билгеләү тәртибе турында” 22.10.2010 № 848 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – ТР МК карары № 848) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2010, № 45, 2064 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 ел, 02 ноябрь, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында” 2012 ел, 07 август, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012 ел, № 59, 2041 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 30 август, № 628 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (далее – Положение о Реестре) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең

республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 68, 2075 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.5. Әлеге Регламентта Татарстан Республикасы мөлкәте булган милек булып түбәндәгеләр күзаллана:

Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

федераль законнарда билгеләнгән очракларда күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

милек иясенә беркетелгән яисә әлеге мөлкәтне алу өчен милек иясе бүлеп биргән акчаларга автоном учреждение сатып алган аеруча кыйммәтле күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

милек иясенә беркетелгән яисә әлеге мөлкәтне алу өчен милек иясе бүлеп биргән акчаларга бюджет учреждениесе сатып алган аеруча кыйммәтле күчемле милек;

Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

күчемле милек.

Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә мөнәсәбәтле:

күчемсез милек;

күчемле милек.

1.6. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә беркетү процедуралары Министрлыкның Мөлкәт идарәсенең Дәүләт мөлкәтеннән файдалану бүлеге тарафыннан башкарыла.

1.7. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү процедуралары Министрлыкның Мөлкәт идарәсенең Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге тарафыннан башкарыла.

1.8. Әлеге Регламент аның 1.5 пунктында күрсәтелгән мөлкәткә мөнәсәбәтле эш итә:

Гариза бирүчеләр балансында булган;

яңа булдырылган;

эксплуатациягә яңа кертелгән;

бер Гариза бирүчедән икенчесенә тапшырылганда.

1.9. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

күпфункцияле үзәкнең дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче ераклаштырылган эш урыны – муниципаль районнардагы авыл җирлекләрендә документлар кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләрне консультацияләү тәрәзәсе;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) дөреслеккә туры килмәвенә китерүче Министрлык хатасы (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) - 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Запросның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 - 4 кушымталарында китерелгән.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү | РФ ГК 294, 296, 299 ст.;<br>Федераль закон № 174-ФЗ 3 ст.;<br>ТР Законы № 35-ЗРТ; 2,7 ст.<br>Федераль закон № 161-ФЗ 11, 13 ст.;<br>Федераль закон № 7-ФЗ, 9.2, 25 ст.<br>Министрлык турында нигезләмә 3.3.4, 3.3.31, 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35, 4.1.9 п. |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органы атамасы | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | Министрлык турында нигезләмә 3.3.4, 3.3.31, 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35, 4.1.9 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карары.<br>Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының | РФ ГК 295, 296 ст.;<br>Министрлык турында нигезләмә 3.3.4, 3.3.31, 3.3.32, 3.3.34, 3.3.35 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучыларның оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы | Гариза Министрлыкка кергән көннән башлап дәүләт хезмәте 22 эш көне эчендә күрсәтелә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе | 1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында яисә оператив идарә хокукында шуның балансында торган гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр кирәк:<br>- Мөрәҗәгать (1 нче кушымта);<br>- Беркетелә торган милек исемлеге кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә;<br>Казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр, казна предприятиеләре өчен – 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;<br>бюджет учреждениеләре өчен - 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган | Министрлык турында нигезләмә 3.3.31, 3.3.34 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;<br>- Баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер.<br>**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә:**<br>Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе.<br>**мәдәни мирас объектларын беркеткән очракта өстәмә рәвештә:**<br>Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:<br>Мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>Муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле.<br><br>2. **Яңа алынган мөлкәтне хуҗалык итү хокукында** | ТР МК карары № 820, 1 п.<br>ТР МК карары № 848, 3 п.<br><br>Федераль закон № 73-ФЗ 48 ст.;<br><br>Федераль закон № 161-ФЗ, 9.2, 25 п.<br>Федераль закон № 7-ФЗ; 4 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | **яисә оператив идарә хокукында** гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр сорала:<br>- Мөрәҗәгать (2 нче кушымта);<br>- Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган һәм мөлкәт сатып алынган акча чыганагы күрсәтелгән беркетелә торган милек исемлеге.<br><br>**Дәүләт учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Беркетелә торган мөлкәт исемлеге гамәлгә куючы белән килештерелгән булырга тиеш.<br><br>**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе.<br><br>3. **Эксплуатациягә яңа кертелгән мөлкәтне хуҗалык итү хокукында яисә оператив идарә хокукында** гариза бирүчегә беркеткәндә түбәндәгеләр сорала:<br>- Мөрәҗәгать (3 нче кушымта);<br>- Объектны төзү рөхсәте күчермәсе;<br>- Объектны эксплуатациягә кертү рөхсәте күчермәсе;<br>- Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган, беркетелә торган милекнең гамәлгә куючы белән килештерелгән исемлеге;<br>- Мөлкәт төзелешенң заказчысы мөрәҗәгате;<br>- Мөлкәтне кабул итеп алу – тапшыру акты проекты. | ТР Законы № 35-ЗРТ;<br>Реестр турында нигезләмә, 1-3, 1.4 п.<br>Министрлык турында нигезләмә 3.3.31, 3.3.34 п.<br><br>ТР МК карары № 820,1 п.<br>ТР МК карары № 848, 3 п<br><br>Федераль закон № 161-ФЗ;<br>Федераль закон № 7-ФЗ, 9.2, 25 ст;<br>ТР МК карары № 820, 1 п.<br>ТР МК карары № 848, 3 п<br>Федераль закон № 7-ФЗ, ст.27;<br>ТР Законы № 35-ЗРТ4 ст.;<br>Реестр турында нигезләмә 1.3, 1.4 п.;<br>Министрлык турында нигезләмә 3.3.31, 3.3.34 п.<br><br>Федераль закон № 161-ФЗ;<br>Федераль закон № 7-ФЗ, 9.2, 25 ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне башка дәүләт предприятиесенең (дәүләт учреждениесенең) **хуҗалык итү хокукыннан яисә оператив идарә хокукыннан алып,** гариза бирүчегә **беркеткәндә** түбәндәгеләр сорала:<br>- Мөрәҗәгать (4 нче кушымта);<br>- Беркетелә торган милекнең кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә исемлеге;<br>- казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр өчен – 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;<br>- бюджет учреждениеләре өчен - 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;<br>- Баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер.<br><br>**Казна учреждениеләре өчен өстәмә:**<br>Тапшыра торган якның гамәлгә куючысының милекне алдыруга ризалыгы.<br>Гамәлгә куючының гариза бирүчегә милекне беркетергә ризалыгы. | Министрлык турында нигезләмә 3.3.14 п.<br><br>Федераль закон № 161-ФЗ;<br>Федерального закона № 7-ФЗ, 9.2, 25 ст.<br><br>ТР МК карары № 820, 1 п.<br>ТР МК карары № 848, 3 п<br><br>Министрлык турында |

| | | |
|---|---|---|
| | **Автоном, бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Тапшыра торган якның милекне алдыруга ризалыгы.<br><br>**Автоном учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**<br>Автоном учреждениенең күзәтү шурасының автоном учреждениенең мөлкәтен алу турында карары.<br><br>**Балалар өчен социаль инфраструктура объекты булган учреждениеләр өчен өстәмә рәвештә:**<br>Җитәкче кул куйган һәм учреждениене гамәлгә куючы белән килештерелгән мөлкәтнең алыну нәтиҗәләре турында эксперт бәяләмәсе (мәгариф учреждениеләре һәм балалар медицина учреждениеләре өчен Федераль агентлыкның 24.03.2006 ел №16-55-88ин/02-12 хаты белән расланган форма буенча).<br>**Мәдәни мирас объектларын беркетү очрагында өчен өстәмә рәвештә:**<br>Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:<br>Мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм | нигезләмә 4.1.9 п.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>ТР МК карары № 820, 1 п.<br><br><br>ТР МК карары № 820, 1 п;<br>Федераль закон № 7-ФЗ, 27 ст.<br>Федераль закон № 124-ФЗ, 13 ст.; |

| | | |
|---|---|---|
| | күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>Муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;<br>Кабул итеп алу – тапшыру акты проекты.<br>Юридик затларның вәкилләре персональ мәгълүматны эшкәртергә язмача ризалык бирәләр (7 нче кушымта).<br>Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тыпшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.<br>Мөрәҗәгатькә теркәлгән документлар төп нөсхәдә (документларга үтеп керү мөмеинлеге булган очракта күчермәләре) бирелә (юллана), яисә җир кишәрлегенә хокуклар алу турында мөрәҗәгатьне кабул итеп алучы Министрлык белгече тарафыннан таныкланган күчермәләрдә.<br>Мөрәҗәгать формасын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать итеп алырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьгә бастырылып түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче тарафыннан);<br>почта аша. | Федераль закон № 73-ФЗ 55 ст.; |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт | 1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРЮЛ) гариза бирүче булган юридик зат турында өземтә, | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | яки Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ТР буенча ФСХИ).<br>2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсеннән (алга таба – ФКП РТ) күчемсез милек турында ЕГРНнан өземтә яки ЕГРНда соралган мәгълүматлар булмавы турында белдерү кәгазе (алга таба – ТР буенча Росреестр).<br>3. Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органыннан мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгыннан (алга таба – ТР Мәдәният министрлыгы).<br>Гариза бирүче әлеге документларны үз инициативасы белән тапшыра ала.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документлар кабул итеп алудан баш тартуга сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмаларда булган өстә күрсәтелгәе документларны таләп итү тыела. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерүләр таләп ителми. | |

| | | |
|---|---|---|
| өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Мөрәҗәгатькә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлмәгән булуы.<br>2. Мөрәҗәгатьтә һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә танықланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән урыннар булуы. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Законнарда дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1. Милек белән эш итүнең башка тәртипләрен күздә тоткан карарларны тиешле тәртиптә кабул ителүе.<br>2. Бу милек белән эш итүнең башка тәртипләрен күздә тоткан законлы көченә кергән суд карары.<br>3. Гариза бирүче тапшырган документларда ниндә дә булса белешмәләрнең булмавы яки дөрес түгел белешмәләр булуы. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы, шул исәптән электрон формада | Запрос кергән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә рәсмиләштерелә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар | |

| | | |
|---|---|---|
| мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору һәм кабул ителү урыннарына, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата, хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка таләпләр | тотыру өчен кирәкле җиһазы һәм мәгълүмати стенд куелган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм аның вакыт буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәкләрнең | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрәстелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында тулы мәгълүматның булуы. | |

| | | |
|---|---|---|
| ераклаштырылган эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып | инвалидлар өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыру белән бәйле булмаган, башка затлар белән берләттән хезмәт күрсәтелергә комачаулаган башка барьерларны үтәргә булышу.<br><br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы.<br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә, күп функцияләр башкаручы үзәкнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыннарында күрсәтелми.<br>Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү турында | |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматны Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яисә телефоннан) яки язмача мөрәҗәгать итеп, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша белешә ала. | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтелми. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре, шулай ук, административ процедураларның күпфункцияле үзәкләрдә, күп функцияле үзәкләрнең дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча ераклаштырылган эш урыннарында

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

запросны кабул итү һәм теркәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карарын әзерләү һәм кабул итү яисә Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат әзерләү;

техник хаталарны төзәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 5 нче кушымтада китерелә.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән

консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан гариза бирүчегә ярдәм итә. Ихтыяҗ булса, запросны рәсмиләштерергә булыша.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (запрос теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Мөрәҗәгатьне кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән мөрәҗәгатьне Бүлеккә бирә (юллый) яки күрсәтелгән документларны почтадан юллый.

3.3.2. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече (алга таба – эш башкару бүлеге) түбәндәгеләрне башкара:

мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итеп ала;

Бүлек белгече белән берлектә мөрәҗәгатьне һәм документларны кабул итмәү өчен документларда әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булмаган очракта мөрәҗәгатьне һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый.

әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигез булган очракта документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече әзерләгән, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Әлеге пункт билгеләгән процедура мөрәҗәгать һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган мөрәҗәгать; гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече Эш башкару бүлегеннән мөрәҗәгатьне һәм документларны алгач, ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

гариза бирүче булып торган оешма - юридик зат турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

күчемсез милек объекты турында ЕГРНнан өземтә яки ЕГРНда соралган мәгълүматлар булмавы турында белдерү кәгазе бирү турында ТР буенча Росреестрга;

мөлкәтнең Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) кертелүе турында белешмә, шулай ук мөлкәтнең музей, архив яки китапханә фондына каравы турында белешмә бирүен сорап ТР Мәдәният министрлыгына.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.4.2. Ведомствоара арадашлык органнары белгечләре ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән 3.4.1 пунктта күрсәтелгән запрослар нигезендә законнарда билгеләнгән тиешле срокларда соралган документларны (белешмәләр) бирәләр.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган белешмәләр (документлар), яисә, соралган белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка юлланган белдерү кәгазе.

3.5. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карарын әзерләү һәм кабул итү яисә Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат әзерләү.

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне алганнан соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырлык әлеге Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшереп чыга.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү турында Министрлык карары проектын әзерли (алга таба – Министрлык карары проекты) яисә Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә,

оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетүдән баш тарту турында хат проекты (алга таба – баш тарту турында хат проекты) әзерли.

Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә җибәрү.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар белешмәләр кергәннән соң җиде эш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.2. Бүлек мөдиренә Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен мөлкәт идарәсе башлыгына (алга таба – Идарә) юллый.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.1, 3.5.2 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң өч эш көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм Бүлек белгеченә юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек белгече Бүлек мөдире, Идарә башлыгы белән килештерелгән, кул кую өчен министрның беренче урынбасарына юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.5.5. Министрның беренче урынбасары Министрлык карары проектына яки баш тарту турында хат проектына кул куя һәм регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Министрның беренче урынбасары кул куйган һәм регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юлланган Министрлык карары проекты яки баш тарту турында хат проекты.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен тапшыру.

3.6.1. Эш башкару бүлеге белгече Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын регистрацияли, гариза бирүчегә Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны бирү өчен билгеләнгән вакыт турында телефоннан хәбәр итә яисә Министрлык карары кабул ителгәннән яки баш тарту турында хатка кул куелганнан соң өч көн эчендә гариза бирүче күрсәткән почта адресына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә теркәлгән һәм гариза бирүчегә юлланган Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.6.2. Гариза бирүче Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны алырга килгән очракта, эш башкару бүлегенең документларны бирүгә җаваплы белгече:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесне таныклаучы документны тикшерә, вәкилнең вәкаләтләрен тикшерә (боерык, ышанычнамә һ.б.);

вәкилгә Министрлык карарын яки баш тарту турында хатны бирә һәм исәп-хисап кенәгәсенә документларның бирелүе турында язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән Министрлык карары яки баш тарту турында хат.

3.7. Дәүләт хезмәте электрон формада, күпфункцияле үзәкләр, күпфункцияле үзәкләрнең дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган ераклаштырылган эш урыны аша күрсәтелми.

3.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хаталарны төзәтү:

Гариза бирүченең Министрлык карарында киткән техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.8.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хаталарны төзәтү турында мөрәҗәгать (6 нчы кушымта);

Министрлык карары;

техник хатаның булуын дәлилләгән документлар.

3.8.2. Министрлык карарында техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатьне гариза бирүче Министрлыкка шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.8.3. Эш башкару бүлеге белгече мөрәҗәгатьне, беркетелгән документлары белән бергә, кабул итеп ала һәм, теркәп, Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт билгели торган процедура мөрәҗәгать һәм документлар бирелгән (кергән) көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карау өчен Бүлек белгеченә юлланган мөрәҗәгать.

3.8.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм Министрлык карарына үзгәрешләр кертү максатыннан Министрлык карарына үзгәрешләр кертү проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.2 – 3.5.5, 3.6.1 – 3.6.2 пунктларында каралган процедураларны гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан хата җибәрелү турында мөрәҗәгать алган көннән соң җиде көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Министрлык карарына үзгәрешләр кертү турында акт.

3.8.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документларны (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, Министрлык карарына үзгәрешләр кертү турында акт (техник хаталарны төзәтеп) Бүлек белгече тарафынан Министрлыкта булган Министрлык карары нөсхәсенә беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен тикшереп тору юлы белән тормышка ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә тормышка ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган

мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

эш башкаруны алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр бирү срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча).

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр куя торган башка норматив хокукый актлар таләпләренең бозылуы алдарак ачыкланган булып, аларның төзәтелгәнлеген тикшерү өчен кирәк булганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре аркасында гариза бирүчеләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуы турында шикаятьләр булганда.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар Министрлыкның дәүләт хезмәт күрсәтүдә катнашучы Министрлык хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә зарланып судка кадәр шикаять бирергә хокуклы.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

Министр урынбасарының, дәүләт хезмәткәренең кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять министр исеменә бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы һәм тәртибе бозылганда;

9) дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтүнең туктатылуы федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда күздә тотылмаган булып та, ул туктатылса.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган атамасы, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда күрсәтелгән шартларны раслый торган документлар теркәлә ала. Бу очракта теркәләгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятькә аны бирүче дәүләт хезмзтен алучы кул куя.

5.7. Шикаять карап тикшерү вакыты – аны регистрацияләгәннән соң 15 көн. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.9. Әлеге Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.10. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Татарстан Республикасы милкендә булган, гариза бирүченең балансында торган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә беркетүгә**
**МӨРӘҖӘГАТЬ**

**Дәүләт оешмасы**: ____________________________________________
(мөлкәтне баланста тотучының атамасы)

____________________________________________________________ исемендә
(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме (соңгысы булса))

Дәүләт мөлкәтен хуҗалык итү (оператив идарә) (кирәкмәгәнен сызарга) хокукында теркәлгән исемлек буенча беркетүегезне үтенәм.

Әлеге мөлкәт беркетелә: **беренче мәртәбә, кабатлап** (кирәкмәгәнен сызарга)
Оператив идарәнең гамәлдәге (соңгы) шартнамәсе №___________ от _______________г.

**Бирелгән мәгълүматларны раслыйм:**

**Гариза бирүченең имзасы: _______________________ м.п. Дата:**
**________________**

Учреждениедән рәсмиләштерү өчен җаваплы зат
________________________________________________________________________
☎___________
ОКПО ___________________________
________________________________________________________________________ ,
Җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе Исеме Әтисе исеме (соңгысы булса)
____________________________________________ нигезендә гамәл кыла
Баланста тотучының юридик адресы: 42____________ , ____________________________ ш.
____________________районы, _____________________________ ур., ☎ _______________

Кушымта:

1. Беркетелә торган милек исемлеге кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә;

- казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр өчен – 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;

- бюджет учреждениеләре өчен - 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш.

2. Булган очракта күчемсез милек объектының кадастр (техник) паспорты күчермәсе.

3. Баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер.

**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә:**

4. Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе.

**Мәдәни мирас объектларын беркеткән очракта өстәмә рәвештә:**

5. Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:

Мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;

Муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле.

Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тыпшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Яңа алынган мөлкәтне хуҗалык итү хокукында дәүләт унитар предприятияләренә, оператив идарә хокукында дәүләт учреждениеләренә беркетүгә**

**МӨРӘҖӘГАТЬ**

**Дәүләт оешмасы**: ____________________________________________
(мөлкәтне баланста тотучының атамасы)

____________________________________________ исемендә
(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме (соңгысы булса))

Дәүләт мөлкәтен хуҗалык итү (оператив идарә) (кирәкмәгәнен сызарга) хокукында теркәлгән исемлек буенча беркетүегезне үтенәм.

**Бирелгән мәгълүматларны раслыйм:**

**Гариза бирүченең имзасы: ________________________ м.п. Дата: ________________**

Учреждениедән рәсмиләштерү өчен җаваплы зат
____________________________________________
☎___________
ОКПО ___________________________
____________________________________________,
Җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе Исеме Әтисе исеме (соңгысы булса)
___________________________________ нигезендә гамәл кыла
Баланста тотучының юридик адресы: 42____________, ____________________________ ш.
____________________районы, ______________________________ ур., ☎ _______________

Кушымта:

1. Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган һәм мөлкәт сатып алынган акча чыганагы күрсәтелгән беркетелә торган милек исемлеге.

**Дәүләт учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**

2. Беркетелә торган мөлкәт исемлеге гамәлгә куючы белән килештерелгән булырга тиеш.

**Автоном һәм бюджет учреждениеләре өчен өстәмә рәвештә:**

3. Аеруча кыйммәтле күчемле милек төрләрен билгеләү турында гамәлгә куючы боерыгы күчермәсе.

Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тапшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Эксплуатациягә яңа кертелгән күчемсез милекне хуҗалык итү хокукында дәүләт унитар предприятияләренә, оператив идарә хокукында дәүләт учреждениеләренә беркетүгә**
**МӨРӘҖӘГАТЬ**

**Дәүләт оешмасы**: ______________________________________________
(мөлкәтне баланста тотучының атамасы)

______________________________________________________________ исемендә
(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме (соңгысы булса))

Дәүләт мөлкәтен хуҗалык итү (оператив идарә) (кирәкмәгәнен сызарга) хокукында теркәлгән исемлек буенча беркетүегезне үтенәм.

**Бирелгән мәгълүматларны раслыйм:**

**Гариза бирүченең имзасы: _______________________ м.п. Дата:**
**_______________**

Учреждениедән рәсмиләштерү өчен җаваплы зат
_____________________________________________________________________
☎___________
ОКПО ___________________________
_____________________________________________________________________________,
Җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе Исеме Әтисе исеме (соңгысы булса)
___________________________________________ нигезендә гамәл кыла
Балансга тотучының юридик адресы: 42____________ , ___________________________ ш.
____________________районы, ____________________________ ур., ☎ _______________

Кушымта:

1. Объектны төзү рөхсәте күчермәсе;
2. Объектны эксплуатациягә кертү рөхсәте күчермәсе;
3. Кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә тапшырылган, беркетелә торган милекнең гамәлгә куючы белән килештерелгән исемлеге;
4. Булган очракта күчемсез милек объектының кадастр (техник) паспортының күчермәсе.
5. Мөлкәт төзелешенең заказчысы мөрәҗәгате;
6. Мөлкәтне кабул итеп алу – тапшыру акты проекты.

Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тапшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

**Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне башка дәүләт унитар предприятиесенең (дәүләт учреждениесенең) хуҗалык итү хокукыннан яисә оператив идарә хокукыннан алып, хуҗалык итү хокукына дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында дәүләт учреждениеләренә беркетүгә**

**МӨРӘҖӘГАТЬ**

**Дәүләт оешмасы**: ________________________________________________

(мөлкәтне балансta тотучының атамасы)

_________________________________________________________ исемендә

(вазыйфа, фамилия, исем, әтисе исеме (соңгысы булса))

Дәүләт мөлкәтен хуҗалык итү (оператив идарә) (кирәкмәгәнен сызарга) хокукында теркәлгән исемлек буенча беркетүегезне үтенәм.

**Бирелгән мәгълүматларны раслыйм:**

| |
|---|
| **Гариза бирүченең имзасы: _____________________ м.п. Дата:**<br>**______________** |
| Учреждениедән рәсмиләштерү өчен җаваплы зат<br>_________________________________________________________________<br>☎___________<br>ОКПО _________________________<br>_________________________________________________________________________ ,<br>Җитәкченең вазыйфасы, фамилиясе Исеме Әтисе исеме (соңгысы булса)<br>________________________________________ нигезендә гамәл кыла<br>Балансta тотучының юридик адресы: 42____________ , _________________________ ш.<br>__________________районы, __________________________ ур., ☎ ______________ |

Кушымта:

1. Беркетелә торган милекнең кәгазь һәм «doc, docx, xml» форматтагы электрон халәттә исемлеге:

казна һәм автоном учреждениеләр, унитар предприятиеләр өчен – 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш;

- бюджет учреждениеләре өчен - 1 данәдә, тегелгән, номерлары сугылган, учреждениене гамәлгә куючы раслаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтер имзалаган булырга тиеш.

2. Булган очракта күчемсез милек объектының кадастр (техник) паспортының күчермәсе..

3. Баш бухгалтер таныклаган беренчел-торгызылу һәм соңгы отчет датасына калдык бәясен раслаучы белешмә яисә баш бухгалтер таныклаган бухгалтер балансы күчермәсе, мөһер.

**Казна учреждениеләре өчен өстәмә:**

4. Тапшыра торган якның гамәлгә куючысының милекне алдыруга ризалыгы.

5. Гамәлгә куючының гариза бирүчегә милекне беркетергә ризалыгы.

**Автоном, бюджет учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре өчен өстәмә рәвештә:**

6. Тапшыра торган якның милекне алдыруга ризалыгы.

**Балалар өчен социаль инфраструктура объекты булган учреждениеләр өчен өстәмә рәвештә:**

7. Җитәкче кул куйган һәм учреждениене гамәлгә куючы белән килештерелгән мөлкәтнең алыну нәтиҗәләре турында эксперт бәяләмәсе (мәгариф учреждениеләре һәм балалар медицина учреждениеләре өчен Федераль агентлыкның 24.03.2006 ел №16-55-88ин/02-12 хаты белән расланган форма буенча).

**Мәдәни мирас объектларын беркетү очрагында өчен өстәмә рәвештә:**

8. Татарстан Республикасы милкендә булган мәдәни мирас объектын саклау буенча кулланучының йөкләмәләре күчермәсе. Аны түбәндәгеләр формалаштыра:

Мәдәни мирас объектын саклау өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына (башкарма хакимиятнең массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә контроль һәм күзәтү функцияләрен башкаручы федераль органы белән килештерү буенча) һәм региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;


Муниципаль районның һәм шәһәр округының башкарма комитеты – җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларына мөнәсәбәтле;


9. Кабул итеп алу – тапшыру акты проекты.

Барлык документларның күчермәсе 1 данәдә тыпшырыла һәм юридик зат җитәкчесе тарафыннан таныклана.

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы




Бүлек белгече
Министрлык карары проектын яки баш тарту турында хат проектын кул кую өчен министр урынбасарына юллый
Кул кую өчен министрга юлланган проектлар
Министр урынбасары
Министрлык карары проектына имза куя яки яки баш тару турындагы хатны имзалый, регистрацияләү өчен эш башкару бүлегенә юллый
Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тару турында имзаланган хат
Министрлык карары проекты
Эш башкару бүлеге белгече
Министрлык карарын яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хатны регистрацияли һәм гариза бирүчегә җибәрә
Гариза бирүчегә җибәрелгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында хат
Регистрацияләнгән Министрлык карары
Эш башкару бүлеге белгече
Гариза бирүчегә Министрлы карарын бирә
Гариза бирүчегә бирелгән Министрлык карары

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

______________________________________

**Техник хатаны төзәтү турында гариза**

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә киткән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Дөрес белешмә:__________________________________________________________
________________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны дөресләп, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы карарына тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм:

________________________ «____»_________ 20______ел. №________;

(документның атамасы)

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Гариза бирүче (гариза бирүчеләр) турында мәгълүмат:

| | |
|---|---|
| Юридик зат реквизитлары *(ОГРН, ИНН, адрес (урнашкан урыны)* | |
| | |
| | |
| Физик зат өчен (юридик затның вәкиле) паспорт мәгълүматлары *(серия, номер, кем кайчан биргән, подразделение коды, теркәлү адресы),* Яшәгән адресы (теркәлү адресы белән туры килмәгән очракта), ИНН | |

| | |
|---|---|
| Телефон, почта адресы һәм (яисә) электрон почта адресы | |
| Беркетелә торган объект турында белешмәләр | |
| Кадастр номеры | |
| Беркетелә торган объектның урнашу урыны | |

________________ ____________________ ( ____________________)
(дата) (имза) (Фамилия, инициаллар)

М.П.(мөһер булса)

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 7 нче кушымта

**Персональ мәгълүматны эшкәртү өчен рөхсәт**

Мин, ______________________________________________________________
“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. Адресында урнашкан Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү үтенеч язуы имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (ышанычнамә буенча вәкил ____ №________________
_______________________________________/______________________/
(вәкилнең исеме, фамилиясе, әтисенең исеме (булса) имзасы)

Үтенеч язуы кабул ителде: «___»__________ 20__ ел.
____________/_______________________________________________/
имза (гаризаны алган белгечнең фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 8 нче кушымта (белешмәлек)

**Республики Татарстан**
**Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне хуҗалык итү хокукларында Татарстан Республикасының дәүләт унитар предприятиеләренә, оператив идарә хокукында Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы дәүләт казна предприятиеләренә беркетү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аны күрсәтүен контрольдә тотучы вазыйфаи затларның реквизитлары**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Хамаев Азат Кыям улы | 221 -40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221 -40-02 | mzio@tatar.ru |
| Министрлыкның дәүләт мөлкәтен файдалану бүлеге<br>Альмукова Инна Наил кызы | 221-40-25 | inna.almukova@tatar.ru |
| Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге мөдире<br>Хәсәнова Ирина Александровна | 221-40-28 | irina.petruhina @tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@.tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**
**Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы<br>Гайнетдинов Ренат Вагыйз улы | 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәте белән идарә итү бүлеге мөдире<br>Рогожкин Максим Анатольевич | 264-76-22 | Maksim.Rogozhkin@tatar.ru |